**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **11.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге составына керүче, Балан-Бүләк авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегендә, Балан-Бүләк авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Балан-Бүләк авылында Ленин урамнары буенча вак таш җәелгән юлларның чокырларын ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Балан-Бүләк авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Балан-Бүләк авылы зиратлары өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;
- Балан-Бүләк авылында янгын сүндергечләр, янгын сундерү ранецлары, янгынга каршы инвентарь сатып алу;
- Балан-Бүләк юлларын кардан чистарту;
- Балан-Бүләк авылы территориясен җәйге чорда чабу;
- Балан-Бүләк авылында коры агачлар, куакларны кисү;
- Балан-Бүләк авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Балан-Бүләк авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне ремонтлау (койма урнаштыру, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Балан-Бүләк авылында урам исемнәре язылган табличкалар әзерләү;
- Балан-Бүләк авылында «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Балан-Бүләк авылы, Балан-Бүләк авылы мәдәният йорты, кибет.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чалпы авыл җирлеге Башлыгы: А.М. Мөхәмәтшин